ГЛАВА ТАТАРСКО-ЧЕЛНИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ГАВАМИ ТЫҢЛАУЛАР
УЗДЫРУ ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАТАР ЧАЛЛЫСЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

тел.(факс): (85549) 3-62-23; e-mail: Tcn.Men@tatar.ru, www:mendeleevsk.tatarstan.ru

Авыл җирлеге башлыгы карары

№ 7 25.09.2024 ел

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Татар Чаллысы авыл җирлегенең
генераль планына үзгәрешләр кертү
проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә,

Карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

2. Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Татар Чаллысы авылы, Җиңү урамы, 3А авылы мәдәният йорты бинасын гавами тыңлаулар уздыру урыны итеп билгеләргә, гавами тыңлаулар үткәрү датасы һәм вакыты - 2024 елның 25 октябрендә 17.00 сәгатьтә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру буенча эш төркемен билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда түбәндәге составта төзергә:

- Кузнецова Татьяна Петровна - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге башлыгы;

-Рябов Александр Владимирович - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының 2 нче округ буенча Татар Чаллысы авыл җирлеге советы депутаты;

- Борисова Лариса Геннадьевна - ТР Менделеевск муниципаль районының 1нче округ буенча Татар Чаллысы авыл җирлеге советы депутаты.

4. Түбәндәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр язма рәвештә авторның исемен, фамилиясен, атасының исемен күрсәтеп, 2024 елның 25 сентябренә кадәр түбәндәге адрес буенча: 423641, ТР, Менделеевск районы,

Татар Чаллысы ав., Җиңү ур., 3А. й. һәм электрон почтага TCn.Men@tatar.ru җибәрелә

(эш көннәрендә - 9.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр)

5. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча: 423641, ТР, Менделеевск районы Татар Чаллысы авылы, Җиңү ур., 3А, шәхсән яисә почта аша (конвертта “муниципаль берәмлекләр чикләрен үзгәртү турында фикер алышу” дигән тамга белән) Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советының карары белән расланган гавами тыңлаулар үткәрү тәртибенә ярашлы рәвештә 2024 елның 25 октябренә кадәр (тел.3-62-23) җибәрелә

6.Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлеге Оештыру комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча билгеләнгән тәртиптә һәм шушы карарда билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

7. Әлеге карарны Татар Чаллысы авылындагы махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштырып, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru «Татар Чаллысы авыл җирлеге» бүлегендә, Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталында урнаштырырга. *

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Менделеевск муниципаль районы
Татар Чаллысы авыл җирлеге башлыгы Т.П.Кузнецова